Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Новотроицк авыл җирлеге составына керүче Күпәрле авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында
ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

«14» апрель 2024 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә гражданнар җыены

КАРАР БИРДЕ:

1. Үзгәрешләр кертергә:

1) түбәндәге редакциядә бәян итеп, гражданнар җыенына чыгарылган һәм кабул ителгән «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Новотроицк авыл җирлеге составына керүче Күпәрле авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 13 ноябрендәге 1 номерлы гражданнар җыены карарына:

«- торак пункт чикләрендә җирле билгеләнештәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту»;

«- тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка ярдәмче станцияләрне һәм алар урнашкан мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау»;

2) 1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп, 2023 елның 13 ноябрендәге 2 номерлы Тукай муниципаль районы Новотроицк авыл җирлеге Күпәрле авылында гражданнар җыены карарына:

«- торак пункт чикләрендә җирле билгеләнештәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;

- тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка ярдәмче станцияләрне һәм алар урнашкан мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау»;

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Новотроицк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы нигезендә махсус мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының рәсми сайтында (tukay.tatarsatan.ru), Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүматы порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Новотроицк авыл җирлеге Башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы
Новотроицк авыл җирлеге советы рәисе,
Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы
Новотроицк авыл җирлеге Башлыгы Д.М. Габделхаева